Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

# КАРАР

№ 5 10 ноябрь 2023 ел

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кисы торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2023 елның 24 ноябрендә ТР, Аксубай районы, Кисы авылы, Ленин урамы, 14 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кисы торак пунктында үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләнсен.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Кисы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән затлардан,контракт буенча хәрби бурычын үтәүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш), 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Киса торак пункты чикләрендә юл япмасы төзү, шул исәптән: туфракны күтәрү, вак таш сатып алу, вак таш белән күмү, тигезләү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

торак пункт эчендә юлларны кышкы тоту, шул исәптән: урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу.

тукталыш павильонын урнаштыру (товарлар сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

2.Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру

- спорт мәйданчыгын урнаштыру ( килешү буенча товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу);

3.Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территорияләрен төзекләндерүне оештыру ;

- Кисы торак пунктында обелискны төзекләндерү (килешү буенча товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу);
- авыл клубы территориясен төзекләндерү ( килешү буенча товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу);

Кисы торак пункты территориясендә үсентеләрне сукалау (ягулык-майлау материаллары сатып алу),

4. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

Кисы торак пунктында суүткәргеч челтәрен ремонтлау (килешү буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А.В.Макаров